

## Уен “Дуслык эстафетасы”

Татар халкында ике кулны биреп күрешү, бер-береңә иминлек, дуслык теләү билгесе. Безнең дуслык нык булсын, көннәребез шатлык белән үтсен.

Кәефе яхшы булган кешеләр белән дуслашырга да, аралашырга да җиңел, күңелгә рәхәт. Ягез әле, балалар, бер-беребезгә ягымлы итеп карап елмаябыз.

- Дуслары булмаган кеше ярты гомер генә яши.
- Дусны ашыкмыйча гына сайла, тапкач – тиз алыштырма.
- 100 сум акчаң булганчы – 100 дустың булсын.
- Дус авырлыкта беленер.
- Дустың булмаса эзлә, тапсаң югалтма.
- Кош канаты белән, кеше дуслык белән көчле.
- Ялгыз агачны җил сындыра.

# Тема: “ Чын дус”

**Максат:**

- Дуслык турында күзаллауны булдыру.
- Ышанычлылык, тугрылык, җаваплылык, үзара ярдәмчеллек кебек уңай кешелекле әхлакый сыйфатларны формалаштыру.



**“Дус – ул ....”**

Мәсәлән:

- Авыр минутларда тыңлый белгән.
- Берсе дә аңламаган вакытта, сине аңлаучы.
- Синең бөтен кимчелекләрең белән, ничек бар шулай кабул итүче.
- Сиңа ошамаса да, һәрвакыт дөресен әйтүче.
- Синнән бернинди дә файда өмет итмәүче.
- Синең өчен үзенең иң кадерле: вакытын, интересларын һәм хаттә үзенең гомерен дә корбан итәргә әзер булган.

Бик биек тауда көтүче яшәгән. Бервакыт яңгырлы бер төндә өч кеше аның ишеген шакыган.

-Минем өем бик бәләкәй, берегез генә керегез.

-Сез кемнәр соң? – дип сораган көтүче.

-Без: Дуслык, Бәхет, Байлык. Иң башлап кайсыбыз керүен үзең хәл ит.

-Укучылар, сез ничек уйлыйсыз? Көтүче кемне кертер?

## **Нәрсә ул дуслык?**

1. Ихтыяҗларның, карашларның, фикерләрнең уртаклыгына, үзара рухи якынлык, бер-береңне ихтирам итү һ.б. хисләргә нигезләнгән мөнәсәбәт.
2. Берәр нәрсә белән мавыгу, аны ярату хисе.

**19-24 балл**

Син яхшы дус. Дусларың сиңа ышана һәм син дә кирәк чагында аларга таяна аласың: алар һәрчак ярдәмгә киләчәк.

**12-18 балл**

Дусларың бар, әмма син, кызганычка каршы, еш кына аларны игътибарсыз калдырасың. Күз алдыңа китер, аларга хәзер бик авыр. Шуңа күрә, иртәгәгә калдырмыйча, бүген үк шалтырат.

**8-11 балл**

Игътибар үзәгендә үзең, яраткан кешең. Тирә-якта-гылар читтә кала. Яхшы дус булыр өчен башкалар белән күбрәк кызыксын, чөнки дусларсыз калуың ихтимал.

# Физкультминутка









*Яшәгән ди янут баласы. (Янут (енот) ул буада яшәүче хайван.) Әнисе аның үзенә генә татлы кыяк үләне алып кайтырга рөхсәт итә. Янут баласы: “Мин зур, мин зур”- дип шатлана.*

*Кулына таяк тотып китә һәм буа янына килеп чыга. Суга карагач ул бик нык курка һәм елый-елый өенә, әнисе янына йөгерә.*





*- Әни анда буадан миңа шундый куркыныч бер нәрсә карап тора, кулына мине кыйнарга таяк та тоткан, буаның икенче ягына чыгарга курыктым,–ди.*







*Әнисе матур итеп елмая да:*

*- Син улым буа янына килеп җиткәч, таягыңны куй һәм матур итеп елмай,– ди. Кечкенә Янут шулай эшли дә һәм әнисе янына шатланып, куанып кайта.*

*- Әни мин буадан карап торучы белән дуслаштым, ул шундый әйбәт икән. Миңа елмайды, кулында таягы да юк иде. Курыкмыйча татлы кыяк үләне алып кайттым, – ди. Әнисе аны иркәләп башыннан сыйпый.*









Үзегез укыган китаплардан, караган кинофильмнардан нинди геройларның дуслыгын үрнәк итеп куя аласыз?




























## Уен “Син дустыңны беләсеңме?”

*(Укытучы сорау бирә, бер укучы тактада яза.*

Сез үзегезнең дусларыгызны яхшы беләсез микән? Игътибарлымы икән сез? Аның нәрсә яратуын, нәрсә белән кызыксынганын, нәрсә турында хыялланганын беләсезме икән? Кулларыгызны күтәрегез әле, кем үзен чын дус дип уйлый.

- Аның иң яраткан дәресе?
- Аның яраткан ел фасылы?
- Кайсы спорт төрен ярата?
- Үсеп җиткәч кем булырга тели?
- Кайсы хайванны ярата?
- Нинди китап укырга ярата?
- Кайсы фәнне ярата?

Дус яшәргә кирәк җир йөзендә,
Дуслар кирәк һәрбер кешегә.
Дуслык булса яшәү дә күңелле,
Уңай була һәрбер эшең дә.